БЕЗДӘ ШУЛАЙ — СЕЗДӘ НИЧЕК?

# «СЕРДӘШЛӘР» ОБЪЕДИНИЛ СЕЛЯНОК



**Несмотря на стремительное развитие современных информационных технологий, библиотека на селе остается основой нравственного воспитания человека, просвещения и в целом прогресса. Ведь книга по-прежнему востребована, ибо она выполняет свою функцию собирателя и хранителя народной памяти.**

Наурузовский филиал сельской библиотеки, а руководит им Резеда Хакимова, сегодня работает по краеведческому направлению. И не случайно, здесь оформлен музей, где выставлены экспонаты — молчаливые свидетели далекого прошлого. Предметы старинного быта дают представление о том, как жили наши деды и бабушки. Собрать старинные вещи библиотекарям было не просто. Помогли в этом односельчане — постоянные читатели — Ф.Абдрашитова, Ф. Мухитова, Р. Аглуллина, А.Уметбаев. Главное место в музее занимают папки и альбомы с историческими материалами, которые рассказывают о селе и людях труда.

В библиотеку приходят как школьники, так и взрослое население. Помимо солидного для села книжного фонда, в читальном зале имеется и периодика. Библиотека получает 22 наименования печатной продукции, в том числе четыре — на родном, татарском языке.

Однако, не только книгами, журналами и газетами интересуются посетители. Сюда селяне приходят и за культурным общением. Вот уже несколько лет, при библиотеке, работает женский клуб «Сердәшләр», под началом и руководством библиотекаря Диляры Габбасовой. Он объединяет домохозяек и женщин пенсионного возраста. Около двадцати человек, с удовольствием посещают заседания клуба. Чем он привлекает? А тем, что селянки находят в клубе место и возможность для самореализации. Они делятся своими интересами и даже маленькими достижениями. На заседаниях обсуждают темы поэзии, домоводства, рукоделия, и даже домашние рецепты. А посиделки за вышивкой или вязанием — для них отдых для души. Общаясь друг с другом, женщины расширяют свой кругозор. Член клуба Васима Янобердина, например, увлекается народной медициной. Она знает много интересных рецептов от болячек и хворей. Увлекательно рассказывает о здоровом образе жизни. А Таския Багданова — хороший цветовод. Летом ее сад благоухает и радует глаз своим разноцветьем. Она информирует подруг о том, как ухаживать за цветами, как выращивать диковинные декоративные растения, делится ростками и семенами. Таския апа проживает недалеко от места захоронения основателя села Наурузово, поэтому ухаживает и следит за порядком на этой могиле. Также, она в первых рядах активистов — помощников имама местной мечети, во время организации религиозных мероприятий. «Сердәшләр» в курсе даже спортивных новостей. О них информирует член клуба Масрура Каримова.

Так, в интересных разговорах за чашкой чая, женщины проводят в библиотеке свое свободное время. Не редки здесь и репетиции, поскольку «сердәшләр» активный участник культурных мероприятий. Они создали одноименную фольклорную группу, которая выступает на концертах, фестивалях. Эти самодеятельные артисты, со своим репертуаром татарских народных песен, всегда востребованы на сцене Наурузовского СДК. Остается только радоваться за этих женщин. Ведь они не замкнулись в себе, в своих семейных делах и проблемах. Живут не только домашними заботами, но и интересными, насыщенными буднями и праздниками.

**И.СУЛЕЙМАНОВА,**
**Пономаревский район.**




# Шигырьләрдән моңлы такыя

**А.Герцен исемендәге район китапханәсендә «Шигъри такыя» дип аталган яшь шигърият сөючеләр бәйгесе узды.**

Бөек Ватан сугышындагы җиңүнең 65 еллыгына һәм Муса Җәлилнең тууына 104 ел тулуына багышланган бу бәйгене китапханә эшчеләре Абдулин районының татар милли-мәдәни мөхтәрияте белән берлектә уздырдылар. Бәйгедә катнашучылар каһарман шагыйрьнең үлемсез әсәрләрен моңлы көйләр белән катнаштырып, рус һәм татар телләрендә, үзәккә үтәрлек итеп башкардылар. Нәтиҗәдә, беренче урынны Покровка авылыннан Кромская Ксения яулап алды. Икенче урында — Иске Шалты авылыннан яшь укытучы Айгөл Гәрәева. Абдрахман авылыннан Эльвина Насибуллина өченче урында. Алар барсыда акчалата премияләр, а бәйгедә катнашучылар — дипломнар һәм татлы призлар белән бүләкләнделәр (фото). Бер мең сум акчаны тәэкил иткән гран-прига Тирес-Усман авылынын Ләйлә Шайдуллина лаек булды. Шигъри бәйге татар милли-мәдәни мөхтәрияте рәисе Ильгизәр Шәймәт улы Зариповның матди ярдәме белән узды һәм тантаналы, моңлы, матур бер бәйрәмгә әверелде.

**Зилә ЗАРИПОВА.**
**Абдуллин районы.**

# Горурланып яши

**«Көннең яктылыгы кояшта,**
**Кукнең матурлыгы йолдызларда,**
**Җир йөзенең гүзәллеге хатын-кызларда».**

**Бу матур сүзләр әлбәттә, бөек бәйрәмгә, аналар көненә багышланган. Һәр кеше горурланып яши үзенең анасы, апасы, сеңелесе, хатыны белән.**

Безнең Иске Әшер авылында да мактауга лаеклы шактый күп кешеләр яши. Шуларның берсе, Матвеевка районы Азамат авылында тугыз балалы гаиләдә туып үскән, Кәмәрия Гайнетдин кызы Бәширова. Ул үзенең бала чакларын матур табигатьле Кинәле елгасы буенда үткәрә. Яшьтән үк колхозның төрле эшләренә катнаша, кече энеләрен, сеңелләрен үстерүдә ярдәмләшә. Шул вакытта, Иске Әшер егете Нәҗип, кызга күз сала. Күп тә үтми, алар өйләнешәләр. Нәҗип абый күп еллар авылда киномеханик, балта остасы, ә лаеклы ялга чыгар алдыннан егерме сигез ел мехтокта электрчы булып эшли. Аның барлык стажы 52 елга тула. Кызганычка каршы, Нәҗип абый 2008 елда дөнья куя.

Кәмәрия апа үзенең бөтен гомерен авыл хуҗалыгына багышлаган. Бик күп еллар «Заветы Ильича» колхозында сыер савучы булып эшли. Алдынгы сыер савучы буларак, берничә ел дәвамында рәсеме колхоз һәм район «Мактау тактасы»нда эленеп тора. Бер урында эшләп, үзенең бар көчен куеп, 40 ел хезмәт көнен тутыра. Әле аңардан башка йортны карарга, балалар тәрбияләргә, мал-туар тотарга да өлгәшкән. Кәмәрия апаның бертуган энесе Фатых Муфазалов та егерме елдан артык «Знамя коммуны» колхозында җитәкче вазыйфасын башкарып урынлы ялга чыга. Бүгенге көндә аның улы Эдуард Фатыхович Матвеевка районында администрация җитәкчесе булып эшли.

«Балаларым, оныкларым килеп хәлләремне белеп торалар», — дип әйтә Кәмәрия апа. Киләчәктә дә шулай сөенеп, шатлыкта яшәргә булсын.

**А.НИЗАМОВ.**
**Матвеевка районы.**